**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2162**
**05.03.2026**

«Игелек чыганагы» ихтыяри ярдәм
(волонтерлык) проектлары конкурсын
оештыру һәм үткәрү

Башкарма комитетның 2025 елның 29 октябрендәге 8858 номерлы Карары белән расланган «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, җирле милли, социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә массакүләм оештырылган ихтыяри ярдәм хәрәкәтен үстерү максатларында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсенә Яр Чаллы шәһәрендә «Игелек чыганагы» ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектлары конкурсын (алга таба – конкурс) 2026 елның март-маенда оештыру һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

Расларга:

1) конкурс турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсның оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча;

3) конкурсның эксперт советы составын, 3 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнарны финанслауны 2026 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлеге буенча каралган акчалар хисабына 80 000,00 (сиксән мең) сум 00 тиен күләмендә, 4 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 5 мартындагы
2162 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Игелек чыганагы»
ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектлары конкурсы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Игелек чыганагы» ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектлары конкурсы (алга таба текст буенча — конкурс) «Добро.Центр – Добрые Челны» «Орион» яшьләр үзәге» МАУ инициативасы буенча Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе ярдәме белән үткәрелә. Конкурс ихтыяри ярдәмне үстерү һәм Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләрне социаль әһәмияткә ия эшчәнлеккә җәлеп итүгә юнәлдерелгән.

2. Әлеге нигезләмә 2026 елдагы конкурста катнашуның тәртибен, үткәрү срокларын һәм шартларын билгели.

3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

Элемтәләр: «Добро.Центр – Добрые Челны», элемтә телефоны 89874195208 Гагинская Елена Владимировна, e-mail: dobro.orion@yandex.ru.

2 бүлек. Максатлар һәм бурычлар

4. Конкурсның максаты – Яр Чаллы шәһәре территориясендә гамәлгә ашырыла торган яңа ихтыяри ярдәм проектларын ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү.

5. Бурычлары:

1) Яр Чаллы шәһәрендә волонтерлык хәрәкәтен үстерү;

2) Яр Чаллы шәһәрендә волонтерлык хәрәкәтен популярлаштыру;

3) булдырылган технологияләр нигезендә социаль проектларны тормышка ашыруның иң яхшы практикаларын тиражлауны билгеләү.

3 бүлек. Катнашучылар һәм катнашу шартлары

6. Конкурста катнашуга волонтерлар, коммерцияле булмаган ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары һәм берләшмәләренең лидерлары, вәкилләре һәм җитәкчеләре, дәүләт һәм муниципаль учреждение хезмәткәрләре, 14 яше тулган, Яр Чаллы шәһәрендә ихтыяри ярдәм (волонтерлык) хәрәкәтен гамәлгә ашыручы инициативалы төркемнәр чакырыла.

7. Конкурска тормышка ашыруның башлангыч стадиясендә булган проектлар кабул ителә.

8. Конкурста катнашу түләүсез.

9. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) «Ярдәм итү өчен туганнар» – сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләрнең, өлкән буынның тормыш сыйфатын күтәрүгә, ятим балаларга, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга булышлык итүгә юнәлдерелгән проектлар;

2) «Гаилә һәм балачак» – гаилә институтын һәм гаилә кыйммәтләрен ныгытуга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән проектлар;

3) «Экологик десант» – үз районында, торак пунктында чисталык булдыру, урамнарны яшелләндерүгә бәйле: шимбә, якшәмбе өмәләре, экологик чаралар үткәрүгә юнәлдерелгән проектлар;

4) «Киләчәккә ышанучылар» – тарихи хәтерне саклау, балалар һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү, хәрби хәрәкәттә катнашучыларга ярдәм күрсәтү өлкәсендәге проектлар;

5) «Милләт сәламәтлеге» – кеше өчен зарарлы һәм куркыныч бәйлелекләрне профилактикалау, сәламәтлек саклау һәм сәламәт яшәү рәвешенең заманча практикаларына булышлык итү, туризмның төрле формаларына ярдәм күрсәтү, балалар, яшүсмерләр һәм зурларга физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру;

6) «Мирас булдыручылар» – халыкның мәдәни традицияләрен саклау, креатив иҗтимагый киңлекләр булдыру һәм үстерүгә, мәдәният һәм сәнгатьнең заманча формаларын үстерүгә юнәлдерелгән проектлар;

7) «Беренчеләр вакыты» – яшьләр инициативаларына булышлык итү, яшьләр мохитенда ихтыяри ярдәмне үстерү, яшьләрнең фәнни-техник һәм сәнгать иҗатын (14+), балалар һәм яшьләрнең һөнәри үзбилгеләнешен үстерүгә юнәлдерелгән проектлар;

8) «Яңгыраш» – практик күнекмәләрне, белемнәрне һәм кыйммәтләрне кешедән кешегә тапшыруга (остазлык) юнәлдерелгән проектлар.

## 4 бүлек. Проектларны бәяләү критерийлары

10. Катнашучылар түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

| Критерийлар | Максималь балл | Критерийның әһәмият коэффициенты |
|---|---|---|
| Проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте | 3 | 2 |
| Проектның оригинальлеге, уникальлеге | 3 | 2 |
| Сан һәм сыйфат буенча көтелгән нәтиҗәләр булу | 3 | 2 |
| Проектның мәгълүмати ачыклыгы | 3 | 2 |

5 бүлек. Үткәрү сроклары һәм тәртибе

11. Конкурс 2026 елның 9 мартыннан 20 маена кадәр берничә этапта үткәрелә:

1) читтән торып үткәрү этабы 1926 елның 9 мартыннан 1 апреленә кадәр (ул көнне кертеп). Заявкалар компаниясенең билгеләнгән срогында конкурсантлар исәп язмасы булдыралар һәм конкурста катнашуга заявканы DOBRO.RU ихтыяри ярдәм өлкәсендәге бердәм мәгълүмат системасында https://clck.ru/3S24es сылтамасы буенча заявка бирәләр һәм шулай ук әлеге нигезләмәгә кушымта нигезендәге форма буенча dobro.orion@yandex.ru электрон почтасына җибәрәләр. Башкарма комитет карары белән расланган эксперт советы конкурска катнашуга заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча, конкурста катнашучылар исемлеген формалаштыра;

2) проектларны яклау 14 апрельдән башлана. Вакыты, урыны һәм төгәл датасы алдан игълан ителә;

3) заявкаларны карау, критерийлар буенча бәяләү, йомгак ясау – 2026 елның 1 маеннан 20 сенә кадәр.

12. Конкурс нәтиҗәләре буенча 8 җиңүче билгеләнә. Җиңүчеләр дипломнар һәм акчалата призлар белән бүләкләнә. Конкурсның барлык катнашучылары электрон рәвештә сертификатлар ала. Тантаналы бүләкләү датасы аерым игълан ителәчәк.

13. Проектны тормышка ашыру буенча хисап иҗади хисап рәвешендә фото һәм видео материаллар белән рәсмиләштерелә. Тормышка ашырыла торган проектларның нәтиҗәләре https://vk.com/crd_chelny төркемендә урнаштырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

«Игелек чыганагы» ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектлары конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә
кушымта

«Игелек чыганагы»
ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектларының
муниципаль конкурсында катнашуга
заявка - анкета

Проект конкурсына тәкъдим ителүченең тасвирламасына түбәндәге позицияләр кертелергә тиеш:

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Гариза бирүченең Ф.И.А.и. | |
| 2 | Гариза бирүченең яше | |
| 3. | Гариза бирүче укый/эшли торган учреждение/берләшмәнең исеме | |
| 4. | Проектның номинациясе | |
| 5. | Проектның исеме | |
| 6. | Проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте | |
| 7. | Проектның максаты | |
| 8. | Проектның бурычлары | |
| 9. | Проектны тормышка ашыру сроклары | |
| 10. | Проектның максатчан аудиториясе | |
| 11. | Проектта катнашучылар саны | |
| 12. | Проект буенча ярдәм алучылар саны | |
| 13. | Проектның чаралар планы | |
| 14. | Проектның сметасы | |
| 15. | Проектны финанслау чыганагы | |
| 16. | Проектның сыйфатлы нәтиҗәләре | |
| 17. | Проектның сан нәтиҗәләре | |
| 18. | Проектның партнерлары | |
| 19. | Социаль челтәрләргә, сайтларга, проектның башка мәгълүмати ресурсларына сылтамалар* | |
| 20. | Проектны презентацияләүгә сылтама* | |
| 21. | Проект турында видеороликка сылтама (булганда)* | |

*Проектның тасвирламасы PDF форматында, шрифт үлчәме – 12, берле интервал белән бирелергә тиеш. Максималь күләм – 10 л. Сылтамалар актив (зәңгәр төстә) булырга тиеш.